

Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе

# Яңа көн

Ноябрь 2018 № 3

*Менә инде уку елының икенче чирегең башлап җибәрдек. Бу айда муниципаль этапта олимпиадалар узачак. Без чын күңелдән анда катнашачак укучыларыбызга зур уңышлар телибез!*

## Бусанда


Яңа чирек башлану белән!

Әниләр көне белән!

Мәктәп күләмендә узган олимпиадаларның нәтиҗәләре

Яңалыклар


***Хөрмәтле укытучылар һәм укучылар!*** *Сезне чын күңелебездән дәүләтебезнең төп бәйрәмнәре – Халыклар бердәмлеге көне һәм Татарстан Республикасы Конституциясе көне белән котлыйбыз. Әлеге ике бәйрәм безнең һәрберебез өчен мөһим, чөнки алар - республикабыз һәм илебезнең үсеш чорында тарих хәтеренә ихтирам билгесе. Барыгызга да ныклы сәламәтлек һәм бәхет телибез!*




Әниләр көне билгеләп үтелмәгән бер генә ил дә юктыр, мөгаен. Россиядә Әниләр көнен күптән түгел генә билгеләп үтә башладылар. Россия Федерациясе Президенты Б.Н.Ельцинның 1998 елның 30 гыйнварында имзаланган указы буенча ул ноябрьнең соңгы якшәмбесендә бәйрәм ителә. Дәүләт Думасының хатын-кызлар, гаилә һәм яшьләр эшләре буенча комитеты Әниләр көнен гамәлгә кую инициативасы белән чыкты.

Әни, әнием, әнкәй! Кадерләп, назлап әйтәбез. Күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз, һәрвакыт янәбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез.
Әни... Өч хәрефтән торган бу сүздә күпме наз, җылылык һәм күңел тойгысы! Әни... Һәр кеше өчен иң кадерле, иң сөйкемле зат ул!
Әни... Аның күзләре шундый мөлаем һәм ягымлы. Әйтерсең, бөтен дөньяның акылын һәм сабырлыгын җыйган диңгез! Ә әнкәйнең куллары иң-иң җылы, иң-иң кадерле куллардыр, мөгаен.
Шул ягымлы куллар сиңа кагылуга, бөтен кайгыларың югала. Ә „балам" дип аркаңнан сыйпаса, сиңа гүя очар канатлар үсә. Ә сүзләре... сүзләре шундый татлы, туң йөрәкләрне эретерлек җылы.
Ә авырсаң... авырсаң, төннәр буе күз йоммыйча, яныңнан да китми инде ул! Бары әнкәйләр йөрәге генә шулкадәр түземле, шәфкатьле.
Нинди генә рәхмәтләр әйтсәк тә, җитмәс төсле. Әниләребез, сезгә саулык-сәламәтлек, кайгысыз-хәсрәтсез тыныч тормыш, озын гомер телибез.

Гомумрәсәй һәм республика олимпиадаларының мәктәп этабында җиңү яулаган укучыларыбызны котлыйбыз! Аларга киләсе этапларда да зур уңышларга ирешүләрен телибез!

Минязов Нияз
Вафина Дина
Султанова Гульфина
Хуснутдинова Резеда
Гильмутдинова Лейла
Галиева Язиля
Хасанова Язиля
Шайхутдинов Амир
Гиниятов Булат
Валеев Булат
Гайнутдинова Гуль-зайнап
Фазлыев Рустем
Сибгатуллин Рифат
Ахмадеева Диляфруз
Зиятдинова Алина
Сибгатуллина Гульса-рия
Адиатуллин Алмаз
Камалова Эльвира
Яруллина Инзиля
Сибгатуллина Ляйса-на
Миннигалеев Радиф
Абдуллина Лейсан
Ахметшина Альфина
Гилазов Инсаф

# Яңалыклар!!!

1 ноябрь көнне Түбән Кама шәһәрендә узган «Ягымлы Татарстан» дигән III Региональ социаль проектлар конкурсында 8 сыйныф укучысы Сибгатуллина Гөлсәрия 2 урын яулады.



Татарстан Республикасы Конституциясе көне уңаеннан, 7 ноябрь көнне сыйныфларда бу бәйрәгә багышланган класс сәгатьләре, әңгәмәләр узды.



Мәктәбебездә 1 –11 нче сыйныф укучылары арасында “Бозда һәм суда сак булырмын!” дигән исем астында республика конкурсы игълан ителде.



Кулланучы хокукларын яклау мәсьәләләре буенча укытучылар катнашында “Түгәрәк өстәл” үткәрелде һәм шушы темага кызыклы һәм файдалы фикерләр тыңланылды.

